СОВЕТ ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 4-05-07; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
20.11.2018

КАРАР
№4-42

2018 елның 18 ноябрендә җирле референдумда
кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 апрелендәге № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне , су чыгаруны оештыру, ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

-Отарка авылында су линиясен алыштыру;

2. Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру
-Пятилетка авылында чишмәне төзекләндерү
-Пятилетка авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларга һәйкәл төзү
3. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру;
- Отарка авыл җирлегенә караучы юлларны кардан чистарту һәм тигезләү

«ӘЙЕ» «ЮК»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 918 номерлы карарын теркәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Отарка
авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе Х.М.Минникаев

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОТАРСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
СОВЕТ ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001235